**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Жуково авыл җирлегенең Берлек торак пунктында 2023 елда үзара салым кертү турында гражданнар җыены карары**

**08 .11. 2022** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131 Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Жуково авыл җирлегенең Берлек торак пунктында гражданнар җыены карар итте:

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Жуково авыл җирлегенең Берлек торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән үзара салым 1000 (бер мең) сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны гражданнарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау өчен таш сатып алу

Берлек.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Жуково авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында (https://tetushi.tatarstan.ru/) һәм " Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында "(https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

**Җитәкче** **Н.А.Борисова**